ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.17,
с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 17йорт,
Акбаш авылы, 423958

Тел.:(85593) 4-14-34, факс:4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04 декабрь 2023 ел №20

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2023 елның 24 июлендәге 13 санлы карары белән расланган Акбаш авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, 1996 елның 31 маендагы «Оборона турында»гы 61-ФЗ санлы Федераль закон, 1997 елның 26 февралендәге «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында»гы 31-ФЗ санлы, 1998 елның 28 мартындагы «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»гы 53-ФЗ санлы, 2023 елның 14 апрелендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы санлы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карарлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәне раслау хакында»гы 719 санлы карары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә һәм җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Акбаш авыл җирлеге» маниципаль берәмлегенә таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты

К А Р А Р  Б И Р Ә:

1. Ниегзләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 1.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Түбәндәге гражданнар хәрби исәпкә алынмый:

а) «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль закон нигезендә хәрби бурычларны үтәүдән азат ителгәннәр;

б) хәрби хезмәт узучылар яисә альтернатив граждан хезмәте узучылар;

в) хәрби-исәп белгечлеге булмаган хатын-кызлар;

г) Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче;

д) офицерларның хәрби исемнәре һәм Россия Федерациясенең тышкы разведка хезмәте һәм Россия Федерациясенең Федераль иминлек хезмәте запасында булучылар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт

хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.Р.Сәхибуллина